ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2022 Казан ш. №329-45/кс-2022

«Родник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2018 №10-96/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2023 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023 елга җайга салынулы оешманың эчә торган суга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Родник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2018 №10-96/кс карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 №10-30/кс, 11.11.2020 №190-47/кс-2020, 17.11.2021 №284-41/кс-2021 карарлары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Родник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2018 №10-96/кс карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 17.11.2021 №284-41/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2018 №10-96/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.202 №329-45/кс-2022 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Родник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга 2019-2023 елларга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Буа муниципаль районы | | |
| 1 | «Родник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Ырынгы авыл җирлеге кулланучылары өчен) | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 20,92 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 21,52 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 21,52 |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 21,56 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 21,56 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 22,42 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 22,42 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 23,67 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 24,93 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге